**Габулла Тукайның” Кәҗә белән Сарык”әкияте.**

**Максат**: Укучыларның иҗади сәләтен үстерү;

әдәби әсәр геойларының сыйфат һәм гамәлләрен анализлау

күнекмәләрен камилләштерү;

тормышта кыенлыкларны җиңү юлларын табарлык мөстәкыйль

фикергә килү күнекмәләре булдыру..

Материал : А. Яхин “Әдәбият. 4 класс”дәреслеге, компьютер, проектор, Г.Тукай “Кәҗә белән Сарык “ әкияте.

**Дәрес барышы:**

**I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.**

1.Оештыру, уңай психологик халәт тудыру.

2. Өй эшен тикшерү.

- Узган дәрестә без Габулла Тукайның” Кәҗә белән Сарык”әкияте белән таныштык.

- Нинди өй эше бирелгән иде? ( Тулысынча эчтәлеген сөйләргә)

-Әйдәгез , кайсыгыз башлый? (Тулысынча эчтәлек сөйлиләр.1,2,3,4,5,6,7)

**Слайд буенча эчтәлек сөйләнә.**

II. **Уку мәсьәләсен кую.**

-Бу әсәр нинди жанрда язылган? ( Әкият жанрында.)

- Ни өчен шулай дип уйлыйсыз?( Чөнки хайваннар сөйләшә.)

- Балалар , кәҗә белән сарык тормышта нинди хайваннар?Сезнең авылда әби-бабайларыгызда сарыклар да, кәҗәләр дә бардыр.Алар нинди? Алар куккак, акылсыз.

-Тормышта сарык белән кәҗә бик куркак, ә әкият ахырында алар җиңүче булып чыгалар. Менә шушыны белү өчен без әкияткә анализ ясарбыз.

Бүгенге дәресебезнең максаты : экияткә анализ ясап авторның әйтәсе теләген ачыкларбыз.

-

**III .Актуальләштерү.**

- Әсәргә анализ бирү тәртибен искә төшерәбез.

**8 нчы слайдта алгоритм.**

Авторның теләген белү өчен экиятне **өлешләргә, вакыйгаларга** бүлергә кирәк. (Тактада бер бала тәртипләп яза бара.)

**- Һәр кисәкнең иң мөһим урынын табып укыгыз.**

**(**4 юллап кына 1әр куплет укырга мөмкин.)

1-Ир белән хатын һәм аларның Кәҗә белән Сарыгы.**Слайд 9.**

2. Кәҗә белән Сарыкның урманга китүе.**Слайд 10.**

- Ни өчен урманга чыгып китәләр?(Хуҗалары җибәрә.)

-Ни өчен чыгарып җибәрәләр?( Үзләренә дә ашарга булмый.)

3.Бүре башы табу. **Слайд 11.**

4.Бүреләрне очрату. **Слайд 12.**

5.Бәладән котылу юлын эзләп табу яки җиңү. **Слайд 13.**

**IV. Уку мәсьәләсен чишү.**

1)- Катнашучыларны санап китегез.

-Төп геройлар кемнәр?

Кәҗә белән Сарык , Бүреләр.

2) Аларның гамәлләре аша сыйфатларын билгелибез.(**Тактада язып барырга.)**

- Алар нинди ? Әкияттән табып хис белән укып күрсәтегез.

3) Охшаш өлешләрен берләштереп әсәрнең планын ике өлешкә генә калдырырга мөмкин.

1-Ир белән хатын һәм аларның Кәҗә белән Сарыгы**.**

2. Кәҗә белән Сарыкның урманга китүе..

3.Бүре башы табу.

4.Бүреләрне очрату.

5.Батыраю, җиңү.

4) Ике өлеш арасында **<u>бәйләнешне</u>** ачыклау.

-Ни өчен алар куркалар?Сәбәбе нәрсәдә? **Куркалар**, чөнки Сарык белән кәҗәнең боткага ит буласылары килми. Котылу юлын уйлап табарга кирәк.

-Кем акыллырак булып чыкты? Сарык.

-Ул нәрсә уйлап таба? Хәйлә .

**-**Нинди хәйлә? **Табып укыгыз.**

-Сарык арттыру алымын куллана. Табып укыгыз.

-Димәк , нәтиҗәдә алар бүреләрне алдап ,хәйләләп җиңәләр.

Монда **сәбәп – нәтиҗә** бәйләнеше. **Слайд.**

Кәҗә белән сарыкның көчләре юк, димәк башны эшләтергә кирәк.Яшисе килә. Шуңа күрә хәйлә коралар.

5)Бу бәйләнеш аша авторның әйтергә теләгән теләген табу.

- Автор нәрсә әйтергә теләгән?

**Автор теләге:** Тормыш юлында кешеләргә авырлыклар, үтә алмаслык булып тоелган , каршылыклар, киртәләр, сынаулар күп очрый. Бу авырлыклар каршында куркып калмаска өйрәтә.

Куркуны җиңәр өчен **<u>акыл көче</u>** кирәк. Сарык белән Кәҗә дә акылларын җигеп башта куркуларын, аннан бүреләрне җиңгәннәр.

**V.Рефлексия - бәяләү этабы.**

- Нәрсә белергә теләгән идек? (Авторның теләген , безгә әйтәсе сүзен.)

- Әсәрнең эчтәлеген сөйләдек;

- Өлешләргә бүлдек;
- Бәйләнешләрне таптык;
- Нәтиҗә ясадык.

**Нәтиҗә: Тормыш юлында авырлыклар, үтә алмаслык булып тоелган, каршылыклар, киртәләр, сынаулар каршында куркып калмаска, акыл белән эш итәргә кирәк.**

Үзбәя.

Өй эше.89 биттәге рәсем буенча хикәя язып килергә. Язарга керешкәнче, ике өлештән торган план төзегез. Сәбәп- нәтиҗә бәйләнешен ачыклагыз.